# КАРАР

**“12” ноябрь 2020 ел** **№ 5**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Югары Курса авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 12 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе тәэелде:

«Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Югары Курса авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган гражданнардан, тумыштан булган инвалидлардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Урта Курса авылы зираты коймасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу һәм ремонтлау;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру, Мәктәп урамында 36-39 нчы йортлар, К. Тинчурин урамында 16 – 19нчы йортлар арасында 5 линия урнаштыру;
- Югары Курса авылында автомобиль юлларын вак таш җәеп тигезләү;
- «Игелек» чишмәсен ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Халык җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 135 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 83 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 83 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегендә Югары курса авылында халык җыенын булып узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. « Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Югары Курса авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 400 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 80 яшьтән узган граждannардан, тумыштан булган инвалидлардан тыш, 800 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Урта Курса авылы зираты коймасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу һәм ремонтлау;
- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляциялләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру, Мәктәп урамында 36-39 нчы йортлар, К. Тинчурин урамында 16 – 19нчы йортлар арасында 5 линия урнаштыру;
- Югары Курса авылында автомобиль юлларын вак таш җәеп тигезләү;
- «Игелек» чишмәсен ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ» “КАРШЫ“

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Югары Курса авылы, Мәктәп урамы, 16а йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина